КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 25 апрель г.Казань № 392

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 – 2024 елларга Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәт тормышка ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 19 июль, 512 нче карары белән расланган «2015 – 2024 елларга Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәт тормышка ашыру» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 – 2024 елларга Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәт тормышка ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 19 июль, 512 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 3 октябрь, 741 нче; 2016 ел, 20 февраль, 104 нче; 2016 ел, 26 май, 354 нче; 2016 ел, 9 ноябрь, 832 нче; 2017 ел, 26 май, 311 нче; 2018 ел, 26 март, 174 нче; 2018 ел, 10 сентябрь, 763 нче; 2019 ел, 17 июнь, 495 нче; 2019 ел, 16 сентябрь, 837 нче; 2019 ел, 25 декабрь, 1201 нче; 2020 ел, 1 июнь, 451 нче; 2020 ел, 9 сентябрь, 814 нче, 2021 ел, 25 март, 169 нчы, 2021 ел, 21 июнь, 485 нче, 2021 ел, 18 сентябрь, 880 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2015 – 2024 елларга Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәт тормышка ашыру» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортының «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау | Программаны Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслауның гомуми күләме 73,2845 млн.сум тәшкил итә, шул исәптән еллар буенча: |

<table>
<tr><td rowspan="13">күләмнәре</td><td colspan="2">(млн.сум)</td></tr>
<tr><td>Ел</td><td>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы</td></tr>
<tr><td>2015</td><td>5,615</td></tr>
<tr><td>2016</td><td>4,37</td></tr>
<tr><td>2017</td><td>4,915</td></tr>
<tr><td>2018</td><td>8,1529</td></tr>
<tr><td>2019</td><td>9,4218</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>5,8684</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>8,4301</td></tr>
<tr><td>2022</td><td>8,8371</td></tr>
<tr><td>2023</td><td>8,8371</td></tr>
<tr><td>2024</td><td>8,8371</td></tr>
<tr><td colspan="2">Искәрмә. Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, Татарстан Республикасы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш»;</td></tr>
</table>

Программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

2015 – 2024 елларда Программаны Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслауның гомуми күләме 73,2845 млн.сум тәшкил итә, шул исәптән еллар буенча:

(млн.сум)

| Ел | Татарстан Республикасы бюджеты акчалары күләме |
|---|---|
| 2015 | 5,615 |
| 2016 | 4,37 |
| 2017 | 4,915 |
| 2018 | 8,1529 |
| 2019 | 9,4218 |
| 2020 | 5,8684 |
| 2021 | 8,4301 |
| 2022 | 8,8371 |
| 2023 | 8,8371 |
| 2024 | 8,8371 |

Программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, Татарстан Республикасы бюджетларының мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

Моннан тыш, Программа чараларын тормышка ашыру өчен чараларны

башкаручыларның төп эшчәнлеген финанслауга бүлеп бирелә торган акчалардан файдалану күздә тотыла.»;

Программага кушымтада:

2.4 пунктның 22 нче графасында «0,26» саннарын «-» тамгасына алмаштырырга;

3.1 пунктның 22 нче графасында «0,997» саннарын «0,85» саннарына алмаштырырга;

«Программа буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән барлыгы» юлында «73,6915» саннарын «73,2845» саннарына алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин